Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты
боерык

17 март 2020 ел № 20

Әлмәт районы һәм Әлмәт шәһәре, Зәй районы һәм Зәй шәһәре, Лениногорск районы һәм Татарстан Республикасы Сарман районы буенча буенча баш дәүләт санитария табибы И.В. Хәйруллинаның «Оешкан коллективларда һәм объектларда чикләү чаралары кертү турында» 2020 елның 13 мартындагы 12 номерлы карарын үтәү йөзеннән, шулай ук, Әлмәт муниципаль районы территориясендә эпидемиологик хәлнең катлаулануына юл куймау максатларында, таҗ инфекциясе буенча дөньяда имин булмаган эпидемиологик вәзгыятьне исәпкә алып:

1. 2020 елның 18 мартыннан 2020 елның 18 апреленә кадәр Әлмәт муниципаль районы территориясендә кешеләр күпләп җыелуга бәйле барлык массакүләм чараларны (мәдәни, спорт, күңел ачу һәм башкалар) чикләргә.

Массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү бүлегенә (Зарипова Л. Н.) халыкка чикләү чаралары турында мәгълүмат бирүне гамәлгә ашырырга.

3. Әлеге боерык аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Район башкарма комитеты
җитәкчесе М.Н. Гирфанов